РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2025 елның 20 марты** **Чистай шәһәре** **№40/4**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Чистай шәһәр
Советының «Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлегендә муниципаль хезмәт
турында»
2019 елның 11 июнендәге 35/2
номерлы карарына үзгәрешләр кертү
хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының» Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 11 июнендәге 35/2 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2019 елның 23 октябрендәге 40/5 номерлы, 2020 елның 11 февралендәге 45/3 номерлы, 2021 елның 22 октябрендәге 10/9 номерлы, 2023 елның 16 февралендәге, 2023 елның 17 августындагы 20/3 номерлы, 2024 елның 27 февралендәге 28/2 номерлы, 2024 елның 30 маендагы 30/6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфасы - Чистай шәһәрендәге вазыйфа «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә җирле үзидарә органы яисә муниципаль

вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар даирәсе белән төзелә.»
1.2. 11 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.»
1.3. 12 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән йә федераль законнарда башкасы каралмаган булса, турыдан-туры буйсынган яисә аңа буйсынган җирле үзидарә органында өченче зат эшләре буенча ышанычлы яисә вәкил булырга;»
1.4. 13 статьяның 3 пунктындагы 5 пунктчасында «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә.
1.5. 20 статьяның 1 пунктына 15 пунктчасын өстәргә:
«15) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы бетерелгәндә, аның шәхси эше саклауга ябылган җирле үзидарә органы функцияләре тапшырылган җирле үзидарә органына яисә аның хокукый варисына тапшырыла.».
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов